ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 26 маендагы** **Чистай шәһәре** **№ 265**

“Чистай муниципаль районы” муниципаль
берәмлеге муниципаль учреждениеләре
җитәкчеләренә 2019 елның 1 гыйнварыннан
31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр,
мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр
турында белешмәләр бирү хакында”

Россия Федерациясе Президентының “2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында”гы 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының “2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында”гы 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-250 номерлы боерыгы белән, “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2013 елның 26 мартындагы 185 номерлы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланган, “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфасына керүче зат тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү хакында, шулай ук “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль учреждениеләре җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында Нигезләмәдә билгеләнгән “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль учреждениеләре җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына белешмәләр бирү вакытын 2020 елның1 августына кадәр (1 августны кертеп) озайтырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов